**III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XLIV СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р №185**

Мөслим «17» июнь 2020 ел

**Аренда түләүләреннән кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 670-р номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениясенә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль казнасын һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен (алга таба - муниципаль милек) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен дә) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары - арендаторлар мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында, 2020 елның апрель - июнь ае өчен, муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектерүне, ләкин кичектерелгән аренда түләүләре срогы 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча башлауны күздә тотучы өстәмә килешүләр төзергә;

б) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында әлеге карар үз көченә кергән көннән, арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә, өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) аренда түләүләрен кичектерү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән арендаторларга – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләре буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә;

б) әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айларында аренда түләвен кичектереп торуны һәм аның тигез өлешләрен 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда түләүне, шулай ук аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә кичектереп тору бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениясенә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында, 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында https://muslumovo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль
районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы
Советы рәисе Р.Х. Муллин